**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 14 июль № 478

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Суд карарларын үтәү өчен торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) күләмен билгеләү турында» 2016 ел, 28 апрель, 257 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Суд карарларын үтәү өчен торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) күләмен билгеләү турында» 2016 ел, 28 апрель, 257 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:»;

түбәндәге эчтәлекле икенче пункт өстәргә:

«2. Әлеге карарны тормышка ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2014 елның 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $8^2$ статьясы нигезендә торак урыны сатып алу өчен торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре исәбенә һәм кысаларында гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин